| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 апрель г.Казань № 255

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 5 сентябрь, 639 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 364 нче; 2018 ел, 16 май, 372 нче; 2021 ел, 25 март, 168 нче; 2022 ел, 19 апрель, 368 нче; 2022 ел, 6 декабрь, 1295 нче; 2023 ел, 21 март, 302 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сентябрь, 821 нче карарын үтәү йөзеннән, телләрнең үсешенә һәм үзара гармонияле багланышына, милләт белән тел мөнәсәбәтләренең тотрыклы балансын саклауга юнәлдерелгән дәүләт сәясәтен алга таба гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының әлеге карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру советы хакындагы нигезләмәнең 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сентябрь, 821 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын һәм телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга кагылышлы башка норматив хокукый актларны гамәлгә ашыруны анализлау.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Совет составыннан М.З.Зәкиевны, М.Х.Сәлаховны, О.А.Третьяковны, К.Г.Яковлевны чыгарырга;

Совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Әхмәдиева Роза Шәйхәйдәр кызын | «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректорын (килешү буенча) |
| Вәлиуллин Ренат Нәкыйф улын | «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы советы рәисе урынбасары, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы советы башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча) |
| Кукушкина Наталья Владимировнаны | «Татарстан Республикасы мариларының милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы советы рәисен (килешү буенча) |
| Миңнеханов Рифкать Нургали улын | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президентын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин